**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**«Яңа Кади авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге гражданнары җыены карары**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Яңа Кади авыл җирлегенең
Утыз Имән торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

20 октябрь 2023 ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 20 октябрендә киләсе мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2024 елда Яңа Кади авыл җирлегенең Утыз Имән торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 550 сум күләмендә үзара салым кертүгә I төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- Утыз Имән торак пунктында «Чәчәкле алан» чишмәсе территориясен төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алуга;

- Утыз Имән торак пунктында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- Утыз Имән торак пунктында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, триммерлар сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү, запас частьләр сатып алу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары;

- Утыз Имән торак пунктында Совет урамындагы 25 метрлы, Киров урамындагы 35 метрлы һәм Дзержинский урамындагы 150 метрлы урам-юл челтәрен төзекләндерү (40-70 мм фракциясендәге вак ташлар сатып алу);

«ӘЙЕ» «ЮК».

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 298 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 151 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 150 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен 1 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены карар кылды:

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге составына керүче Утыз Имән торак пунктында халык җыены булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип танырга.

Киләсе мәсьәлә буенча: «2024 елда Яңа Кади авыл җирлегенең Утыз Имән торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 550 сум күләмендә үзара салым кертүгә I төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- Утыз Имән торак пунктында «Чәчәкле алан» чишмәсе территориясен төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алуга;

- Утыз Имән торак пунктында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- Утыз Имән торак пунктында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, триммерлар сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү, запас частьләр сатып алу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары;

- Утыз Имән торак пунктында Совет урамындагы 25 метрлы, Киров урамындагы 35 метрлы һәм Дзержинский урамындагы 150 метрлы урам-юл челтәрен төзекләндерү (40-70 мм фракциясендәге вак ташлар сатып алу);

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә: Утыз Имән авылы, Совет урамы, 51нче йорт. Чирмешән муниципаль районының рәсми интернет-сайтында бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Яңа Кади авыл җирлеге башлыгы М.М.Әминов